РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
НОВОЧЕЧКАБСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ЧӘЧКАП
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 май 2024 ел №3-84

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»
2023 елның 6 февралендәге 3-65 номерлы
ТР Буа муниципаль районының Яңа Чәчкап авыл
җирлеге Советының карарына үзгәрешләр
кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә ярашлы рәвештә, Яңа Чәчкап авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 6 февралендә 3-65 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Чәчкап авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта:

1 пунктчаның икенче абзацында «, дача» сүзен төшереп калдырырга;

2 пунктчаның беренче абзацында «, фатир өлешләрен;» сүзләрен өстәргә;

3 пунктчаның беренче абзацында «, торак йортларның өлешләре;» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 3 пунктта:

3.2 пунктның өченче абзацында. «рөхсәт ителергә мөмкин» сүзләрен «рөхсәт ителә» сүзләре белән алыштырырга;

3.3 пунктчасының өченче абзацын үзгәртегез һәм түбәндәге редакциядә бәян итегез:

«Салым ташламасы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлеге территориясендә урнашкан һәр төргә салым салуның бер объектына карата салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына карамастан, салым түләүченең сайлавы буенча бирелә.»

1.3. 5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге карарның 3 пунктындагы 3.3 пунктчасы нигезләмәсе 2023-2024 елгы салым чорларында физик затларның мөлкәтенә салымны исәпләү белән бәйле хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.»

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (http//buinsk.tatarstan.ru) рәсми рәвештә басылып чыккан көннән законлы көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет рәисе, ТР Буа муниципаль районының
Яңа Чәчкап авыл җирлеге башлыгы Д.Д.Абдрахманова